**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

22.12.2017 1561-п

**Татарстан Республикасы Казан шәһәрендә урнашкан Югары Кабан, Урта Кабан һәм Түбән Кабан күлләренең су саклау зоналарын һәм яр буе саклау полосаларын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Су кодексының 26, 65 маддәләре; 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы “Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында” Федераль законның 32 маддәсе; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 31 декабрендәге 1532 номерлы «“Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында” Федераль законның 32 маддәсенең 1, 3 – 13, 15 өлешләре нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан дәүләт кадастр исәбен, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрын алып баруны һәм Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында булган мәгълүматларны бирүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына (аның территориаль органнарына) җибәрелә яки тапшырыла торган документларны тапшыру кагыйдәләрен раслау турында» карары; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 январендагы 17 номерлы “Җирлектә су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклау полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында” карары; Россия Федерациясе Табигать министрлыгының 2010 елның 29 сентябрендәге “Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан федераль милектә булган һәм Россия Федерациясе субъектлары территориясендә урнашкан су объектларын яки аларның өлешләрен саклау чараларын гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе тапшырган вәкаләтне гамәлгә ашыру буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында” 425 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 325 нче номерлы “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре” карары; Максатчан фаразланган күрсәткечләргә ирешүгә юнәлтелгән һәм Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан су мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга субвенция рәвешендә бирелә торган акчалар хисабына финанслана торган

мерпориятиеләрнең 2017 елда Татарстан Республикасы буенча исемлеге нигезендә һәм 2016 елның 21 июнендәге № 16МЭ-14Ф "Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектлары: Архиерей (Тарлаш) күле, Кавал күле, Танайка елгасы, Уратма елгасы, Шилнә елгасы, Бәрле елгасы, Нурминкә елгасы, Урта Кабан күле, Түбән Кабан күле, Югары Кабан күле, Петьялка елгасы, Үләмә елгасы, Мохово күленең су саклау зоналарын һәм яр буе саклау полосаларының чикләрен билгеләү" дәүләт контракты кысаларында башкарылган эшләр нәтиҗәләре буенча

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зонасының һәм яр буе саклау полосасының киңлеген, 2006 елның 03 июнендәге 74-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Су кодексының 65 маддәсе нигезендә әлеге чикләрдә хуҗалык эшчәнлеген һәм бүтән төр эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып билгеләргә:

1.1. Югары Кабан күле:

Югары Кабан күленең яр буе саклау полосасы киңлеге: ярның авышлыгы $3^{o}$ һәм күбрәк градус булганда – 50 м; ярның авышлыгы $3^{o}$ кимрәк булганда – 40 м; нуль яки кире авышлык булганда– 30 м.

1.2. Урта Кабан күле:

Урта Кабан күленең су саклау зонасы киңлеге – 50 м.

Урта Кабан күленең яр буе саклау полосасы киңлеге: ярның авышлыгы $3^{o}$ һәм күбрәк градус булганда – 50 м; ярның авышлыгы $3^{o}$ кимрәк булганда – 40 м.

1.3. Түбән Кабан күле:

Түбән Кабан күленең су саклау зонасы киңлеге – 50 м.

Түбән Кабан күленең яр буе саклау полосасы киңлеге: ярның авышлыгы $3^{o}$ һәм күбрәк градус булганда – 50 м; ярның авышлыгы $3^{o}$ кимрәк булганда – 40 м; нуль яки кире авышлык булганда – 30 м.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (М.Р. Галиәкбәров) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәүгә җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловка йөкләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев